**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.05.2017 № 269

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 9 июнендә теркәлде, № 3959

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2012 ел, №592 боерыгы белән расланган, Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итү буенча дәүләт функцияләрен башкару буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Норматив-хокукый актны Россия Федерациясе законына туры китерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2012 ел, №592 боерыгы белән расланган, Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итү буенча дәүләт функцияләрен башкару буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламентына (11.01.2013 ел, № 5, 25.09.2014ел, № 518, 02.06.2015 ел, № 366, 02.07.2016 ел, № 377 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән), яңа редакциядә бәян итеп (кушымта итеп бирелә), үзгәреш кертергә:

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2012 ел, №592 боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 02.05.2017 ел, № 269 боерыгы редакциясендә)

**Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итү буенча дәүләт функцияләрен башкару буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламенты**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕ АТАМАСЫ

1.1. Бу регламент билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне (алга таба – күзәтчелек һәм контрольлек) хәл итү буенча дәүләт функцияләрен башкаруда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) административ процедураларының (гамәлләре) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясе атамасы: билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне (алга таба – дәүләт функциясе) хәл итү.

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ТУРЫДАН-ТУРЫ ҮТӘҮЧЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАШКАРМА ДӘҮЛӘТ ХАКИМИЯТЕ ОРГАНЫ АТАМАСЫ

1.2. Дәүләт функциясен башкаручы булып Министрлык тора.

Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручылар булып Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрының халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге мәсьәләләргә җаваплы урынбасары (алга таба – министр урынбасары) боерыгы (распоряжение) нигезендә тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән Министрлыкның

социаль яктан аз якланулы категорияләр өчен эш урыннарын булдыру бүлегенең һәм Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи затлары (административ җаваплылыкка тарту турында беркетмәләр төзү ягыннан) (алга таба – вазыйфаи затлар) тора.

“Бердәм тикшерүләр реестры” федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – тикшерүләрнең бердәм реестры) мәгълүматлар кертү Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан хәл ителә.

Министрлык дәүләт функцияләрен башкарганда Татарстан Республикасы прокуратура органнары (алга таба – прокуратура органы) һәм Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) белән берлектә эшли.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕ ҖАЙГА САЛУЧЫ НОРМАТИВ-ХОКУКЫЙ АКТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

1.3. Дәүләт вазыйфасы түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2002, № 1, ст. 1, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, , 2002, № 1, ст. 3, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында” 19 апрель, 1991 ел, № 1032-1 Россия Федерациясе законнар җыентыгы (алга таба – № 1032-1 Росия Федерациясе Законы) (Ведомости Съезда народных депутатов РСФСР и Верховного Совета РСФСР, 1991, № 18, ст. 565, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ Федераль закон (алга таба – Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, , 1995, № 48, ст. 4563, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 2 май, 2006 ел, № 59-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, № 19, ст. 2060, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Мәгълүмат, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында” 27 июль, 2006 ел, № 149-ФЗ Федераль закон ((Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, № 31, ст. 3448, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26 декабрь, 2008 ел, № 294-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2008, № 52, ст. 6249, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – “Электрон имза турында” Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, № 15, ст. 2036, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм хосусый эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында” 30 июнь, 2010 ел, № 489 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – № 489 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, ,2010, № 28, ст. 3706, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” 28 апрель, 2015 ел, № 415 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – № 415 Хөкүмәт карары) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2015, № 19, ст. 2825, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куярга ярамавы турында кисәтү тутыру һәм җибәрү, юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан мондый кисәтүгә каршы килүләрне тапшыру һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында” 10 февраль, 2017 ел, № 166 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Хокукый мәгълүматлар рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль, бастырып чыгару номеры (0001201702140002);

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органнары, муниципаль контрольлек органнары тарафыннан документлар һәм (яки) мәгълүматларны үз карамагында тоткан башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яки дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан соратып алына торган документлар һәм (яки мәгълүматлар исемлеген раслау турында 19 апрель, 2016 ел, № 724-р Россия Федерациясе Хөкүмәте боерыгы (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2016, № 18, ст. 2647, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелә торган инвалидны реабилитацияләүнең яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын, инвалид баланы реабилитацияләү яки абилитацияләүнең индивидуаль программасын һәм аларның формаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру рәтибен раслау турында” 31 июль, 2015 ел, № 528н Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (Хокукый мәгълүматлар рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2015, 24 август, бастырып чыгару номеры:0001201508240045, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып)

“Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, дәүләт күзәтчелеге һәм контрольлеге функцияләренең федераль дәүләт стандартын раслау турында” 30 апрель, 2013 ел, № 181н Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы ((Российская газета, 2013, 14 август, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында” 30 апрель, 2009 ел, № 141 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга

таба – № 141 Россия Икътисалый үсеш министрлыгы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 12 май, 2003 ел, № 16-ЗРТ Ттатарстан Республикасы Законы (“Республика Татарстан”, 2003, 17 май, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында” 19 июнь, 2006 ел, № 39-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы (“Республика Татарстан”, 2006, 27 июнь, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында” 24 июль, 2006 ел, № 60-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы (алга таба – № 60-ТРЗ ТР Законы ("Республика Татарстан”, 2006, 28 июль, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эшмәкәрләрдә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 04.05.2007 ел, № 170 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 170 ТР МК карары) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, № 19, ст. 0673, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

ТР Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эшмәкәрләрдә инвалидлар өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигеләмә) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, № 19, ст. 0673, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007 ел, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, № 33, ст. 1178, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр тутыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында” от 12.11.2007 ел, № 346 Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (алга таба – 12.11.2007 № 346 Министрлык боерыгы) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, », 2007, № 46, ст. 1833. кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен башкаруның административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында” 31.12.2012 ел, № 1192 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы” журналы, 2013, № 7, ст. 0194, кертелгән үзгәрешләрдән чыгып).

## КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕК ОБЪЕКТЛАРЫ

1.4. Күзәтчелек һәм контрольлек объектлары булып, оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы, исемлектәге хезмәткәрләренең уртача саны кимендә 35 кеше тәшкил иткән һәм үзләренә Россия Федерациясе законы һәм Татарстан Республикасы законы нигезендә инвалидларны эшкә алу өчен квота билгеләнгән хосусый эшмәкәрләр (алга таба – юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр, уртак рәвештә “эш бирүче” дип тә аталалар) тора, дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан тыш, шулай ук устав (тупланма) капиталы инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе кертеменнән торган иҗтимагый инвалидлар берләшмәләреннән һәм алар тарафыннан оештырылган оешмалардан, шул исәптән хуҗалык итүче ширкәтләрдән һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук үзләренә карата закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә бетерү турында карар кабул ителгән оешмалардан тыш.

## КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕК ПРЕДМЕТЫ

1.5. Күзәтчелек һәм контрольлек предметы булып эш бирүчеләр тарафыннан билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу буенча бурычларны үтәү ягыннан Россия Федерациясе законында билгеләнгән таләпләрнең, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи заты күрсәтмәләрен үтәве, гражданнарның гомере һәм сәламәтлегенә зыян китерүне кисәтү чараларын, мондый зыянның аянычлы нәтиҗәләрен бетерү чараларын үткәрү тора.

## КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕКНЕ ХӘЛ ИТКӘНДӘ МИНИСТРЛЫКНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.6. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә хокуклы:

1) хезмәт таныклыгын күрсәтеп һәм юридик зат җитәкчесенә, хосусый эшмәкәргә тикшерелә торган юридик затка, хосусый эшмәкәргә карата тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы (распоряжение) күчермәсен тапшырып, күчмә тикшерү үткәрү өчен хосусый эшмәкәрдә булуга;

2) планлы күчмә тикшерү үткәрүгә үзенә карата тикшерү үткәрелә торган оешма белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган экспертлар, эксперт оешмаларын җәлеп итүгә;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, документлар һәм (яки) мәгълүматларны үз карамагында тоткан дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яки дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары

карамагындагы оешмалардан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматларны, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән срокта һәм тәртиптә, шул исәптән электрон рәвештә, бушлай соратып алуга;

4) тикшерү үткәрү турында распоряжение яки боерык кабул ителгәннән соң юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүматлар соратып алуга, күчмә тикшерү үткәрелгәндә юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлар алуга – күчмә тикшерүгә кадәр документар тикшерү үткәрелмәгәндә;

1.7. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә бурычлы:

1) мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм мондый очракларга киртә кую буенча Россия Федерациясе законы нигезендә бирелгән вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы күләмендә үтәүгә;

2) Россия Федерациясе законнарын үтәүгә, үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик затның, хосусый эшмәкәрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүгә;

3) тикшерүне, билгеләнеше нигезендә, аны үткәрү турында министр, министр урынбасары распоряжениесенә яки боерыгына туры китереп үткәрүгә;

4) тикшерүне фәкать хезмәт бурычларын үтәү вакытында гына үткәрүгә, күчмә тикшерүне фәкать хезмәт таныклыкларын, министр, министр урынбасары распоряжениесе яки боерыгы күчермәсен күрсәтеп кенә, ә № 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 5 өлешендә күздә тотылган очракта – тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында документ күчермәсен күрсәтеп кенә үткәрүгә;

5) юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү үткәрүне карап торуга һәм тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә комачаулык итмәүгә;

6) тикшерү үткәрүне карап торган юридик зат җитәкчесена, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына керүче мәгълүматлар һәм документлар тапшыруга;

7) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен, хосусый эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре, шул исәптән тикшерү акты белән таныштыруга;

8) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен, хосусый эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән таныштыруга;

9) ачыкланган закон бозу фактлары буенча күреләчәк чараларны билгеләгәндә, әлеге чараларның закон бозу фактлары авырлыгына туры килүен, аларның кешеләр гомере һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Росия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр)

объектларына, Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле музей предметлары һәм музей коллекцияләренә, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, илкүләм китапханә фонды составына керүче аеруча зур тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә зыян салу ихтималын, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр китереп чыгару ихтималын исәпкә алуга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрнең, юридик затларның хокукларының һәм законлы мәнфәгатьләренең нигезсез чикләнүенә юл куймауга;

10) юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр шикаять белдергәндә, үзләренең гамәлләренең нигезле булуын Росия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә дәлилләүгә;

11) № 294-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә, тикшерү үткәрү срокларын үтәүгә;

12) юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән Россия Федерациясе законында күрсәтү-тапшыру күздә тотылмаган документлар һәм башка мәгълүматлар таләп итүгә;

13) күчмә тикшерү башланганчы, юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, хосусый эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча аларны бу Административ регламент нигезләмәләре белән таныштыруга;

14) тикшерүләрне учетка алу журналында (юридик затның, хосусый эшмәкәрнең мондый журналы булганда) үткәрелгән тикшерү турында язып куюга.

1.8. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә хокклы була алмый:

1) Министрлык вәкаләтләренә кермәгән мәҗбүри таләпләр үтәлешен тикшерүгә;

2) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив-хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законына туры килмәүче таләпләр үтәлешен тикшерүгә (2017 елның 1 июленнән “һәм Россия Федерациясе законына туры килмәүче” дигән сүзләрне “, шулай ук куллануның мәҗбүрилеге Россия Федерациясе законында күздә тотылмаган норматив документлар таләпләрен үтәү” дигән сүзләргә алыштырыла);

3) Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләр үтәлешен тикшерүгә;

4) юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, хосусый эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүгә, мондый тикшерүне № 294-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә күздә тотылган нигез буенча үткәрелү очрагыннан тыш ;

5) тикшерү объектлары булып тормаучы яки тикшерү предметына кермәүче документлар, мәгълүматлар таләп итүгә, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен тартып алуга;

6) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынып, дәүләт, коммерция, хезмәт сере, закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматлар

таратуга, Россия Федерациясе законында күздә тотылган очраклардан тыш;

7) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын арттыруга;

8) юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә үзләренең хисабына контрольлек чаралары үткәрү турында күрсәтмәләр бирүгә яки тәкъдим итүгә;

9) юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән, рөхсәт документларын кертеп, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яки дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалар карамагында булып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматларны таләп итүгә;

10) юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән тикшерү башлану датасына кадәр документлар, мәгълүматлар таләп итүгә. Министрлык тикшерү үткәрү турында распоряжение яки боерык кабул ителгәннән соң, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүматлар соратып алуга хокуклы.

## ҮЗЛӘРЕНӘ КАРАТА КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕК ЧАРАЛАРЫ ХӘЛ ИТЕЛӘ ТОРГАН ЗАТЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

1.9. Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, хосусый эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәргәндә хокуклы:

1) тикшерү үткәрүне турыдан-туры карап торуга, тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә;

2) Министрлыктан, аның вазыйфаи затларыннан тикшерү предметына керүче һәм № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә тапшыру күздә тотылган мәгълүматларны алуга;

3) Министрлыкка ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) документларны үз карамагында тоткан башка дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яки дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан кергән документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән танышуга;

4) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документларны һәм (яки) мәгълүматларны үз инициативасы белән дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органына тапшыруга;

5) тикшерү нәтиҗәләре белән танышуга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышуын, алар белән, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәвен күрсәтүгә;

6) тикшерү үткәргәндә юридик затның, хосусый эшмәкәрнең хокукларын бозуга китергән Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмау), Россия Федерациясе законы нигезендә, административ тәртиптә һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерүгә;

7) тикшерүдә катнашуга Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне яки Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне җәлеп итүгә.

1.10. Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр күзәтчелек һәм контрольлекне хәл иткәндә Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә хокукка каршы килүе танылган Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләре (гамәл кылмау) аркасында китерелгән зыянны, кулдан ычкындырылган файданы (алынмый калынган керемне) кертеп, гражданлык законы нигезендә тиешле бюджетлар средстволары хисабына каплауга хокуклы.

Министрлыкның вазыйфаи затларының хокукка каршы килми торган гамәлләре белән юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә китерелгән зыян капланылмый, федераль законнарда күздә тотылган очраклардан тыш.

1.11 Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, хосусый эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле тикшерү үткәргәндә бурычлы:

1) күчмә тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларның һәм күчмә тикшерү үткәрүдә катнашучы экспертларның, экспертлар оешмалары вәкилләренең юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан эшчәнлекне хәл кылуда файдаланыла торган корылмаларга, биналарга, бүлмәләргә керүен тәэмин итүгә;

2) үзе катнашырга яки мәҗбүри таләпләрне үтәү чараларын оештыру һәм үткәрүгә җаваплы вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итүгә;

3) тикшерү үткәрүгә вәкаләтле Министрлыкның вазыйфаи затларына, тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча, Россия Федерациясе законы нигезендә тапшыру күздә тотылган мәгълүматлар һәм документлар, шул исәптән телдән һәм язмача аңлатмалар тапшыруга;

4) Министрлыктан башка документлар тапшыру таләбе белән нигезле запрос алынганда яки документлар тикшерү вакытында документларда хаталар, каршы килүләр һәм (яки) документлардагы мәгълүматларга туры килмәүләрнең ачыклануы турында мәгълүматлар алынганда, Министрлыкка, запрос яки мондый мәгълүматлар алынганнан соң ун эш көне эчендә, запроста күрсәтелгән документларны яки аңлатмаларны җибәрүгә.

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТАСВИРЛАМАСЫ

1.12. Дәүләт функциясен үтәүнең нәтиҗәсе булып юридик затның, хосусый эшмәкәрнең халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алганда эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозуы яки бозмавын ачыклау тора.

Дәүләт вазыйфасын үтәү нәтиҗәләре булып тора:

тикшерү акты (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган тикшерү актының типовой формасы нигезендә);

юридик затның, хосусый эшмәкәрнең тикшерүләрне учетка алу журналы булганда, бу журналга ууткәрелгән күчмә тикшерү турында язып кую (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган тикшерүләрне учетка алу журналы формасы); (

№ 294-ФЗ Федераль законның 13.3 статьясы һәм РФ Хөкүмәтенең № 415 карары нигезендә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүматлар;

мәҗбүри таләпләрне бозу ачыкланган очракта:

халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә (үрнәк формасы бу Административ регламентка № 5 кушымтада китерелгән).

беркетмә:

РФ КоАП 5.42 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу турында;

РФ КоАП 19.7 статьясында күздә тотылган административ хокук бозу турында.

Дәүләт функциясен үтәүгә нигез булып Министрлыкка гражданнардан, оешмалардан алынган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) алынган мәгълүматлар торган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт функциясен башкару нәтиҗәләре буенча № 59-ФЗ Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР

### ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ ТУРЫНДА ХӘБӘР ИТҮ ТӘРТИБЕ

2.1.Министрлыкның урнашу урыны: Казан ш., Волгоград ур., 47 й., тел. (843) 557-20-01, факс 520-92-87.

2.2.Министрлыкның эш графигы: шимбә, якшәмбе һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькәчә (җомга көнне – 16.45 сәгатькәчә), төшке аш вакыты – 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькәчә.

2.3. Министрлыкның «Интернет» челәрендәге рәсми сайты адресы: http://mtsz.tatarstan.ru.

Электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru.

Министрлыкка дәүләт функциясен башкару нәтиҗәләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420044, Казан ш., Волгоград ур., 47 й.

2.4. Министрлыкның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүматлар тапшырыла:

Министрлык телефоннары аша: (843) 557-20-93; 557-20-30;

Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба “Интернет” челтәре): - http://mtsz.tatarstan.ru;

Министрлык бүлмәләрендәге мәгълүмати стендларда;

Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә – язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә).

2.5. Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) урнашу урыны турында мәгълүматлар, аларның адреслары һәм телефоннары бу Административ регламентка №1 кушымтада китерелгән.

2.6. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең урнашу урыны, телефоннары, эш графиклары турында мәгълүматлар тапшырыла:

Министрлык телефоннары аша: 557-20-01, 557-21-13, бу Административ регламентка №1 кушымтада күрсәтелгән халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре телефоннары аша;

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында-http://mtsz.tatarstan.ru;

Министрлыкның, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең бүлмәләрендәге мәгълүмати стендларда.

2.7. Бу Административ регламент турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында (http://mert.tatarstan.ru) урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафынан дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентларының бердәм реестрына кертелә.

2.8. Дәүләт функциясе һәм аны башкару тәртибе турында мәгълүматлар ирештерү турыдан-туры Министрлык һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре бүлмәләрендә, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, электрон элемтә яки телефон элемтәсеннән файдалану нигезендә, автомат рәвештә мәгълүматлар ирештерүне кертеп, «Интернет» челтәре аша, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләр) бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Бердәм портал) һәм (яки) “Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы” төбәк порталын (http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) кертеп, хәл ителә.

2.9. Министрлыкның рәсми сайтында, Министрлыкныц мәгълүмати стендларында түбәндәге мәгълүматлар урнаштырыла:

1) кушымталары белән, бу Административ регламент тексты (стендларда – тексттан өзекләр);

2) ел саен расланыла торган закон бозуларны профилактикалау программасы;

3) үтәлешен бәяләү контрольлек предметы булып торган мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив-хокукый актлар яки аларның аерым өлешләре исемлеге, шулай ук тиешле норматив-хокукый актлар текстлары;

4) мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләләре буенча, шул исәптән мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча бастырып чыгарылган кулланмалар, семинарлар һәм конференцияләр, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре үткәрү турында мәгълүматлар, башка ысуллар белән урнаштырылган башка мәгълүматлар турында мәгълүматлар. Мәҗбүри таләпләр үзгәртелгән очракта мәҗбүри таләпләрне билгеләүче яңа норматив-хокукый актларның эчтәлеге, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларны гамәлгә кертү сроклары һәм тәртибе турында аңлатмалар, шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле оештыру, техник чаралар үткәрү турында тәкъдимнәр урнаштырыла;

5) елына кимендә бер тапкыр күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итү тәҗрибәсен даими гомумиләштерү буенча мәгълүматлар, шул исәптән, закон бозуларга юл куймау максатында юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр тарафыннан

күрелергә тиешле чараларга карата тәкъдимнәр белән, мәҗбүри таләпләрне бозуның еш очрый торган очракларын күрсәтеп;

6) Министрлык боерыгы белән расланган планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планы (алга таба – План).

## КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕК ЧАРАЛАРЫН ҮТКӘРГӘН ӨЧЕН ЮРИДИК ЗАТЛАРДАН ҺӘМ ХОСУСЫЙ ЭШМӘКӘРЛӘРДӘН ТҮЛӘҮ АЛЫНМАУ ТУРЫНДА

2.10. Күзәтчелек һәм контрольлек чаралары өчен юридик затлардан, хосусый эшмәкәрләрдән түләү алынмый, шул исәптән, тикшерүләр үткәрүгә җәлеп иткән очракта, экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре күрсәтүдән дә түләү алынмый..

## ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН БАШКАРУ СРОГЫ

2.11. Тикшерү (документар, шулай ук күчмә) үткәрү срогы 20 эш көненнән арта алмый.

Кече предприятиегә карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми срогы 50 сәгатьтән арта алмый.

2.12. Кече эшмәкәрлек субъектлары булып торучы эш бирүчеләргә карата планлы күчмә тикшерү үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар алу зарурилыгы очрагында, тикшерү үткәрү министр (министр урынбасары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне хәл итү өчен кирәкле срокка туктатылып торырга мөмкин, әмма ун эш көненнән дә күбрәк булмаган вакытка. Тикшерү үткәрүне кабат туктатып тору рөхсәт ителми.

Тикшерү үткәрүне туктатып торуның гамәлдә булу срогына кече эшмәкәрлек субъектының территориясендә, биналары, корылмалары, бүлмәләрендә, башка объектларында Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге тикшерүгә бәйле гамәлләре туктатып торыла.

2.13. Катлаулы тикшеренүләр үткәрү зарурилыгына бәйле чыгарма очракларда, планлы күчмә тикшерү үткәрүче Министрлыкның вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре буенча, планлы күчмә тикшерү үткәрү срогы министр тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма күп дигәндә 20 эш көненә генә, кече предприятиеләргә карата – күп дигәндә илле сәгатькә.

2.14. Юридик затны, хосусый эшмәкәрне планлы тикшерүләр күп дигәндә өч елга бер тапкыр үткәрелә.

## ПЛАНЛЫ ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮГӘ НИГЕЗЛӘР

2.15. Планлы тикшерүләр Министрлык тарафыннан эшләнеп раслана торган еллык планнар нигезендә үткәрелә. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык

планнары (алга таба – Планнар) № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокта прокуратура органнарына таныштырылырга һәм алар белән килештерелергә тиеш. Министр тарафыннан расланган Планнар Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

2016 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәрге чорда “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 24 июль, 2007 ел, № 209-ФЗ Федераль законның 4 статьясындагы нигезләмәләренә туры китереп кертелгән эш бирүчеләргә карата планлы тикшерүләр № 294-ФЗ Федераль законның 26.1статьялары таләпләренә туры китереп оештырыла һәм үткәрелә.

2.16. Планлы тикшерүне еллык планга кертүгә нигез булып түбәндәге вакыйгадан соң өч ел узу тора:

юридик затны, хосусый эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу;

юридик затка, хосусый эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерү үткәрү;

юридик затның, хосусый эшмәкәрнең, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән тиешле өлкәдәге федераль башкарма хакимият органына эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен хәл итүне башлап җибәрү турында тапшырылган уведомлениесе (әлеге уведомлениене тапшыруны таләп иткән эшләр башкару яки хезмәтләр күрсәтү очрагында) нигезендә, эшмәкәрлек эшчәнлеген башлап җибәрү вакыйгасынанн соң.

## ПЛАННАН ТЫШ ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮГӘ НИГЕЗЛӘР

2.17. Планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып тора:

1)мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан үтәү срогы чыгу;

2) Министрлыкка алынган гражданнар, шул исәптән хосусый эшмәкәрләр, юридик затлар мөрәҗәгатьләрен һәм гаризаларын, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларынан алынган мәгълүматларны карап тикшерү яки башлангыч тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге фактлар турында Министрлыкның вазыйфаи затының нигезле күрсәтмәсе:

а) кешеләр гомере һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Росия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) объектларына, Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле музей предметлары һәм музей коллекцияләренә, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, илкүләм китапханә фонды составына керүче аеруча зур тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә зыян салу курынычы туу, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы туу;

б) кешеләр гомере һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Росия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) объектларына, Россия Федерациясе Музей фонды составына кертелгән аеруча кыйммәтле музей предметлары һәм музей коллекцияләренә, шул исәптән Россия Федерациясе Архив фондының уникаль документларына, илкүләм китапханә

фонды составына керүче аеруча зур тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә зыян салу, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу;

в) кулланучылар хокукларын бозу (хокуклары санга сугылмаган гражданнар кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген хәл итүче органга мөрәҗәгать иткән очракта – мөрәҗәгать итүче үзенең санга сугылмаган хокукларын яклауны (торгызуны) сорап юридик затка, хосусый эшмәкәргә мөрәҗәгать иткәндә һәм мондый мөрәҗәгать карап тикшерелмәгәндә яки мөрәҗәгать итүченең таләпләре канәгатьләндерелмәгәндә);

3) Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте поручениеләре нигезендә һәм прокуратура органнарына алынган маттериаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләбе нигезендә бастырып чыгарылган Министрлык боерыгы (распоряжение).

2.18. Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны билгеләү мөмкинлеге бирмәгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук бу Административ регламентның 2.17 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлардан торган гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт итә алмый. Мөрәҗәгатьтә яки гаризада бәян ителгән мәгълүматлар бу Административ регламентның 2.17 пунктындагы 2 пунктчасы нигезендә планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып тора алган очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты, мөрәҗәгать яки гаризаның авторына нигезле шикләнүләре булганда, мөрәҗәгать иткән затны билгеләүгә карата акылга сыешлы чаралар күрүгә бурычлы. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документлар рәвешендә җибәрелгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, фәкать мөрәҗәгать итүченең идентификация һәм аутентификация бердәм системасында мәҗбүри авторизация узуын күздә тоткан мәгълүмати-коммуникация технологияләре средстволарыннан файдалану нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелгән шартларда гына планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт итәргә мөмкин.

2.19. Мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларны бу Административ регламентның 2.17 пунктында күрсәтелгән фактлар турында мәгълүматларны карап тикшергәндә, моңа кадәр алынган мондый мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре, шулай ук тиешле юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә карата үткәрелгән контрольлек чаралары нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.20. Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи затлары, мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган зат турында тиешле мәгълүматлар, мәҗбүри таләпләрне бозу турында яки бу Административ регламентның 2.17 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар булмаганда, алынган мәгълүматка башлангыч тикшерү үткәрергә мөмкин. Башлангыч тикшерү үткәрү барышында гаризалар һәм мөрәҗәгатьләр җибәргән, мәгълүматлар тапшырган затлардан өстәмә мәгълүматлар һәм материаллар соратып алу (шул исәптән телдән) буенча чаралар күрелә, Министрлык карамагындагы юридик зат, хосусый эшмәкәр документлары тикшерелә, кирәк булганда, юридик затлардан, хосусый эшмәкәрләрдән башка гына һәм әлеге затларга мәгълүмат тапшыру һәм Министрлык таләпләрен үтәү

бурычларын йөкләмичә генә хәл ителә торган контрольлек чаралары үткәрелә. Башлангыч тикшерү кысаларында юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән алынган мәгълүматка карата аңлатмалар сорап алынырга мөмкин, әмма мондый аңлатмалар һәм башка документлар тапшыру мәҗбүри булып тормый.

2.21. Мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куйган затларны башлангыч тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозу турында яки бу Административ регламентның 2.17 пунктында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүматлар алыну ачыкланганда, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты бу Административ регламентның 2.17 пунктындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү турында нигезле күрсәтмә әзерли. Башлангыч тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик затны, хосусый эшмәкәрне җаваплылыкка тарту чаралары кабул ителми.

2.22. Тиешле тикшерү башланганнан соң аны оештыруга нигез булып торган мөрәҗәгатьнең яки гаризаның аноним булуы ачыкланганда, яки мөрәҗәгатьтә яисә гаризада белә торып ялган мәгълүматларның күрсәтелгәнлеге билгеләнгәндә, министр, министр урынбасары карары буенча башлангыч тикшерү, планнан тыш тикшерү туктатыла.

2.23. Министрлык, гаризаларда, мөрәҗәгатьләрдә белә торып ялган мәгълүматлар күрсәтелгәндә, гражданиннан, шул исәптән юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән, әлеге затлардан алынган гаризаларны, мөрәҗәгатьләрне карап тикшерүгә бәйле рәвештә тотылган чыгымнарын түләтү турында судка дәгъва белән мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

2.24. Юридик затка, хосусый эшмәкәргә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү Министрлык тарафыннан, мондый эш бирүчеләрнең эшчәнлеген хәл кылу урыны буенча прокуратура органы белән килештереп, бу Административ регламентның 2.17 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча үткәрелергә мөмкин,

КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕКНЕ ҮТКӘРҮНЕ ТУРЫДАН-ТУРЫ ХӘЛ КЫЛУЧЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР

2.25. Дәүләт функциясен турыдан-туры үтәүчеләр булып бу Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар тора.

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле Министрлыкның вазыйфаи затлары исемлеге Министрлыкның 12.11.2007 ел, №346 боерыгы белән расланган.

№294-ФЗ Федераль законны бозган өчен юридик затларның, хосусый эшмәкәрләрнең җаваплылыгы

2.26. №294-ФЗ Федераль законны бозуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулачы, тикшерүләр үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) мәҗбүри таләпләрне бозуларны юкка чыгару турында Министрлык күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ МИНИСТРЛЫКНЫҢ, АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛЫРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

Тикшерү үткәргәндә Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының җаваплылыгы

2.27. Министрлык, аның вазыйфаи затлары, тикшерү үткәргәндә үзләренең функциясен, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәгән, хокукка каршы гамәлләр кылган (гамәл кылмау) очракта, Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

3. ЮРИДИК ЗАТЛАРГА, ХОСУСЫЙ ЭШМӘКӘРЛӘРГӘ КАРАТА КУЕЛА ТОРГАН МӘҖБҮРИ ТАЛӘПЛӘР

3.1. Үтәлеше Министрлык тарафыннан контрольдә тотылып, юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге, аларны билгеләүче норматив-хокукый актлар исемлеге, тикшерү вакытында юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә күрсәтелә торган документлар исемлеге бу Административ регламентның № 2 кушымтасында китерелгән.

3.2. Министрлык мәҗбүри таләпләрен бозуларны профилактикалау максатыннан чыгып, бу Административ регламентның 3.3-3.15 пунктлары нигезендә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куярга ярамау турында кисәтүләр тапшыра.

3.3. Министрлыкта алынган мөрәҗәгатьләр һәм гаризаларда (авторы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларда урын алган мәҗбүри таләпләрне бозуга әзерләнү яки бозу билгеләре турында мәгълүматлар булганда, мәҗбүри таләпләрне бозуның гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүе яки әлеге аянычлы нәтиҗәләрнең турыдан-туры килеп чыгу куркынычын тудыруы турында расланган мәгълүматлар булмаганда, һәм юридик зат, хосусый эшмәкәр моңа кадәр тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаганда, Министрлык юридик затка, хосусый эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куярга ярамау турында кисәтү ясый һәм юридик затка, хосусый эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин

итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта кисәтүдә билгеләнгән срокта Министрлыкка хәбәр җиткерергә тәкъдим итә.

3.4. Кисәтү җибәрү турында карарны министр, министр урынбасары яки Министрлык боерыгы нигезендә вәкаләт бирелгән башка вазыйфаи зат, бу Административ регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлар булганда, кабул итә.

3.5. Кисәтүне тутыру һәм җибәрү Министрлыкның вазыйфаи заты бу Административ регламентның 3.3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны алганнан соң 30 календарь көненнән дә соңга калмыйча хәл ителә.

3.6. Кисәтүдә күрсәтелә:

а) Министрлык атамасы;

б) кисәтү датасы һәм номеры;

в) юридик зат атамасы, хосусый эшмәкәр фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

г) мәҗбүри таләпләр, норматив-хокукый актлар, әлеге таләпләрне күздә тоткан структур берәмлекләрен кертеп;

д) юридик затның, хосусый эшмәкәрнең нинди гамәлләренең (гамәл кылмау) мәҗбүри таләпләрне бозуга китерүе яки китерә алуы турында мәгълүмат;

е) юридик затка, хосусый эшмәкәргә мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрүне тәкъдим итү;

ж) юридик затка, хосусый эшмәкәргә кисәтүне үтәү турында Министрлыкка уведомление җибәрүне тәкъдим итү;

з) юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан кисәтүне үтәү турында уведомлениене җибәрү срогы (кисәтү җибәрелгәннән соң кимендә 60 календарь көне);

и) Министрлыкның элемтәгә керү өчен мәгълүматлары, почта адресын һәм электрон почта адресын кертеп, шулай ук каршы килүләрне, кисәтүне үтәү турында уведомлениене тапшыруның мөмкин булган башка ысуллары.

3.7. Кисәтүдә юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан мәгълүматлар һәм документлар тапшыру таләбе күрсәтелә алмый.

3.8. Кисәтү кәгазьдә почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки юридик зат, хосусый эшмәкәр өчен уңайлы булган башка төрле ысул белән җибәрелә, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, бу Административ регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән кисәтү җибәрү турында карар кабул иткән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон

имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрүне кертеп, шул исәптән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән яисә юридик зат, хосусый эшмәкәрнең рәсми сайтында Россия Федерациясе законы нигезендә урнаштыру мәҗбүри булып торган мәгълүмат составында күрсәтелгән юридик хатның, хосусый эшмәкәрнең электрон почта адресына, яисә “Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша җибәрелә.

3.9. Кисәтүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча юридик зат, хосусый эшмәкәр Министрлыкка каршы килүләрне тапшырырга мөмкин.

3.10. Каршы килүләрдә күрсәтелә:

а) юридик зат атамасы, хосусый эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

б) салым түләүче – юридик зат, хосусый эшмәкәрнең идентификация номеры;

в) юридик зат, хосусый эшмәкәр исеменә җибәрелгән кисәтү датасы һәм номеры;

г) кисәтүдә күрсәтелгән, мәҗбүри таләпләрне бозуга китергән яки китерә алырдай юридик зат, хосусый эшмәкәр гамәлләренә (гамәл кылмау) карата фикерне нигезләү.

3.11. Каршы килүләр юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан Министрлыкка кәгазьдә почта аша заказлы хат белән яки юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтле хосусый эшмәкәрнең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, кисәтүдә күрсәтелгән Министрлыкның электрон почта адресына, яисә кисәтүдә күрсәтелгән башка төрле ысуллар белән җибәрелә.

3.12. Министрлык каршы килүләрне карап тикшерә, карап тикшерү йомгаклары буенча юридик затка, хосусый эшмәкәргә каршы килүләр алынганнан соң 20 эш көне эчендә бу Административ регламентның 3.8 пунктында билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрә. Каршы килүләрне карап тикшерү нәтиҗәләре Министрлык тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау чараларын оештыру һәм үткәрү максатында һәм юридик затларның, хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын һәм ирекләрен чикләүгә бәйле булмаган башка максатларда кулланыла.

3.13. Каршы килүләр булмаганда, юридик зат, хосусый эшмәкәр кисәтүдә күрсәтелгән срокта Министрлыкка кисәтүне үтәү турында уведомление җибәрә.

3.14. Кисәтүне үтәү турында уведомлениедә күрсәтелә:

а) юридик зат атамасы, хосусый эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

б) салым түләүче – юридик зат, хосусый эшмәкәрнең идентификация номеры;

в) юридик зат, хосусый эшмәкәр исеменә җибәрелгән кисәтү датасы һәм номеры;

г) кисәтүне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматлар.

3.15. Уведомление юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан кәгазьдә почта аша Министрлыкка яки юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтле затның, хосусый эшмәкәрнең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә кисәтүдә күрсәтелгән Министрлыкның электрон почта адресына яки кисәтүдә күрсәтелгән башка төрле ысуллар белән җибәрелә.

## 4. ТИКШЕРҮ ҮТКӘРГӘНДӘ ЮРИДИК ЗАТ, ХОСУСЫЙ ЭШМӘКӘР ТАРАФЫННАН КҮРСӘТЕЛӘ ТОРГАН ДОКУМЕНТЛАР

Тикшерү үткәрү максаты һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан күрсәтелергә тиешле документлар исемлеге, шулай ук мондый документларның формаларын раслауга нигез итеп алынган норматив-хокукый актлар исемлеге бу Административ регламентка №3 кушымтада китерелгән.

## 5. АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАР (ГАМӘЛЛӘР) СОСТАВЫ, ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ ҺӘМ АЛАРНЫ БАШКАРУ СРОКЛАРЫ, АЛАРНЫ БАШКАРУ ТӘРТИБЕНӘ КАРАТА ТАЛӘПЛӘР, ШУЛ ИСӘПТӘН ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАЛАРНЫ (ГАМӘЛЛӘР) БАШКАРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

5.1. Дәүләт функциясе документар тикшерү һәм (яки) күчмә тикшерү рәвешендә үткәрелә торган планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыру юлы белән хәл ителә.

5.2. Дәүләт функциясе түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләрен планлаштыру һәм әзерләү;

планлы күчмә тикшерү үткәрү;

планлы документар тикшерү үткәрү;

планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү;

планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү;

планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

тикшерү актында билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу буенча закон бозу фактлары булганда, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү.

5.3. Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы бу Административ регламентка № 4 кушымтада китерелгән.

5.4. Россия Федерациясе законында күздә тотылган очракларда дәүләт функциясен башкаруны туктатып тору рөхсәт ителә.

## “ПЛАНЛЫ КҮЧМӘ ҺӘМ ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮНЕ ПЛАНЛАШТЫРУ ҺӘМ ӘЗЕРЛӘҮ” АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.5. “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләрен планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасын башлауга нигез булып, еллык Планны әзерләү һәм аның проектын, килештерү өчен, прокуратура органнарына җибәрү срокларының җитүе тора.

5.6. Министрлыкның социаль яктан якланылмаган категорияләр өчен эш урыннарын булдыру бүлеге начальнигы, еллык План әзерләү өчен, җаваплы эш башкаручы (җаваплы эш башкаручылар) (алга таба – Планны әзерләү буенча җаваплы эш башкаручы) билгели.

Башкару срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәр килүче елның 1 августыннан да соңга калмыйча.

3.7. Планны әзерләү буенча җаваплы эш башкаручы түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

1) Кирәк булганда Федераль салым хезмәтеннән, шул исәптән электрон рәвештә, бу административ Регламентның 1.6 пунктындагы 3 пунктчасы нигезендә билгеләнгән тәртиптә, түбәндәге документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратып ала:

юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар;

хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар;

алдагы календарь елында хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саны турында мәгълүматлар;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрыннан мәгълүматлар;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең №489 карары белән расланган, Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрендә күздә тотылган форма буенча еллык План проектын төзи, аны социаль яктан якланылмаган категорияләр өчен эш урыннарын булдыру бүлеге начальнигы, министр урынбасары һәм министр белән килештерә;

башкару срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәр килгән елның 23 августыннан да соңга калмыйча;

3) планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәрге елның 1 сентябренә кадәр, прокуратура органына кәгазьдә (электрон рәвештәге күчермәсе белән), почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки, “Электрон имза турында” Федераль закон нигезендә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (алга таба – көчәйтелгән квалификацияле электрон имза) белән имзаланган электрон документ рәвешендә еллык План проектын килештерүгә җибәрә.

5.8. Планны әзерләү буенча җаваплы эш башкаручы, прокуратура органы тарафыннан еллык план проекты карап тикшерелгәннән һәм тәкъдимнәр кертелгәннән соң:

1) прокуратура органыннан алынган тәкъдимнәрдән чыгып, еллык план проектына төзәтмәләр кертә;

2) еллык план проектын, кертелгән үзгәрешләр белән, Министрлыкның социаль яктан якланылмаган категорияләр өчен эш урыннарын булдыру бүлеге начальнигы белән килештерә;

3) еллык план проектын министрга раслауга җибәрә;

4) еллык планны раслаганнан соң, министр аны кәгазьдә (электрон рәвешендәге күчермәсе белән) почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, тиешле органга җибәрә.

Башкару срогы: расланылган еллык планны прокуратурага җибәрү – планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәр килгән елның 1 ноябренә кадәр.

5.9. Планны әзерләү буенча җаваплы эш башкаручы расланган еллык планны Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыруны оештыра.

Башкару срогы: агымдагы календарь елының 31 декабренә кадәр.

5.10. Еллык планга үзгәрешләр кертү, № 489 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән билгеләнгән очракларда, раслау документлары (мәсәлән, юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан яки хосусый эшмәкәрләренең бердәм дәүләт реестрыннан юридик затны, хосусый эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу, бетерү

(реестрдан төшереп калдыру) турында язу кертү хакында өземтәләр) булганда рөхсәт ителә.

Еллык планга үзгәрешләр кертү министр боерыгы белән хәл ителә. Еллык планга кертелгән үзгәрешләр турында мәгълүматлар билгеләнгән тәртиптә, үзгәрешләр кертелгәннән соң 3 эш көне эчендә, кәгазьдә (электрон рәвештәге күчермәсе белән) почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә тиешле прокуратура органына җибәрелә һәм үзгәрешләр кертелгәннән соң 5 эш көне эчендә Министрлыкның рәсми сатына урнаштырыла.

5.11. Министр, План нигезендә эш бирүчегә карата тикшерү үткәрү өчен, Министрлыкның социаль яктан якланылмаган категорияләре өчен эш урыннарын булдыру бүлегенең вазыйфаи затлары арасыннан җаваплы эш башкаручыны (җаваплы эш башкаручылар) (алга таба – җаваплы эш башкаручы) билгели.

Башкару срогы: эш бирүчегә карата тикшерү башланганчы кимендә өч атна кала яки Планны төзегәннән соң.

5.12. Җаваплы эш башкаручы “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләрен планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

1) тикшерү башланырга кимендә 2 атна кала, №141 Россия Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы белән расланган тикшерү үткәрү турында боерык яки типовой распоряжение формасы нигезендә, тикшерү үткәрү турында боерык (распоряжение) проекты әзерли;

Тикшерү үткәрү турында боерыкта (распоряжение) күрсәтелә:

министрлык атамасы, шулай у дәүләт контрольлеге (күзәтчелек ) төре (төрләре);

тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларның, эксперт оешмалары вәкилләренең фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре, вазыйфалары;

үзләренә карата тикшерү үткәрелә торган юридик зат атамасы яки хосусый эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, юридик затларның (аларның филиаллары, вәкиллекләре, аерым структур подразделениеләре) урнашу урыннары яки хосусый эшмәкәрләрнең факттагы эшчәнлек урыннары;

тикшерү максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү срогы;

тикшерү үткәрүгә хокукый нигезләр;

тикшерелергә тиешле мәҗбүри таләпләр;

тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларын ирешү өчен кирәкле контрольлек чаралары исемлеге һәм аларны үткәрү сроклары;

дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) хәл итү буенча административ регламентлар исемлеге;

тикшерү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле булган юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

тикшерүнең башлану һәм тәмамлану датасы;

башка мәгълүматлар – типовой распоряжение формасында яки министр, министр урынбасары боерыгында күздә тотылган очракта;

2) министрның (министр урынбасары) тикшерү үткәрү турында боерыкка (распоряжение) кул куюны тәэмин итә;

3) планлы тикшерү үткәрүне башлау турында министр, министр урынбасары распоряжениесе яки боерыгы күчермәсен почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) һәм, юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында электрон почта адресы булганда яки юридик зат хосусый эшмәкәр моңа кадәр Министрлыкка электрон почта адресын тапшырганда, юридик затның, хосусый эшмәкәрнең электрон почта адресы аша җибәрелгән, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә яки уңайлы башка ысул белән юридик затка, хосусый эшмәкәргә уведомление җиткерүне тәэмин итә;

башкару срогы: юридик затка, хосусый эшмәкәргә уведомление җибәрү – тикшерү башланырга кимендә өч эш көне кала.

5.13. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү буенча карарлар кабул итү критерийләре булып бу Административ регламентның 2.16 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.14. “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып тора:

тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыны билгеләү;

тикшерү үткәрү турында боерык (распоряжение);

юридик зат, хосусый эшмәкәр исеменә җибәрелгән тикшерү үткәрү турында уведомление.

5.15. “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсен теркәү-саклау бу Административ регламентның 5.14 пунктында күрсәтелгән уведомлениеләр, боерык (распоряжение) күчермәләрен исәпкә алу һәм саклау юлы

белән эш материалларында, шулай ук Министрлыкта делопроизводство алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә, электрон рәвештә документлар мәгълүматларын аерым саклау рәвешендә хәл ителә.

## “ПЛАНЛЫ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ” АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.16. “Планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып тиешле юридик затны, хосусый эшмәкәрне юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә тикшерүләр үткәрү буенча Министрлыкның еллык планына кертү, “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасының тәгәлләнүе, шулай ук документар тикшерүдә түбәндәгеләргә ирешә алмау мөмкинлеге тора:

эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен хәл итүне башлап җибәрү турында уведомлениедәге мәгълүматларның һәм Министрлык карамагындагы юридик зат, хосусый эшмәкәр документларындагы мәгълүматларның тулылыгына һәм дөреслегенә инануга;

тиешле контрольлек чарасын үткәрмичә генә юридик зат, хосусый эшмәкәр эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяләүгә.

5.17. Җаваплы эш башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

1) Министрлык боерыгында (распоряжение) билгеләнгән срокта юридик затка, хосусый эшмәкәргә килеп, хезмәт таныклыгын күрсәтә һәм юридик зат җитәкчесе, хосусый эшмәкәргә тикшерү үткәрү турында боерык (распоряжение) күчермәсен тапшыра, юридик зат җитәкчесенә, хосусый эшмәкәргә контрольлек чаралары максатлары, бурычлары, тикшерү үткәрүгә нигезләр, төрләре һәм күләме, аны үткәрү сроклары һәм шартлары турында хәбәр итә;

башкару срогы: юридик затка, хосусый эшмәкәргә килгәч;

2) документларда тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле мәгълүматларны өйрәнә;

3) юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан түбәндәге нигезләмәләрнең (бу Административ регламентка №2 кушымта нигезендә, тикшерү үткәргәндә эш бирүчеләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр) үтәлешен тикшерә:

а) инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә алу өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары санының инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнар таләпләренә туры килүен;

б) фактта эшләүче инвалидлар санының инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарының тиешле санына туры килүен;

в) юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган билгеләнгән срокларда инвалидларны һөнәри реабилитацияләү һәм аларга эшкә урнашуга ярдәм итү эшчәнлеген хәл кылу өчен кирәкле мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген;

г) юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган билгеләнгән срокта инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген;

4) Кирәк булганда, планлы күчмә тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча документлар һәм материаллар, шулай ук юридик зат җитәкчесеннән, хосусый эшмәкәрдән язмача аңлатмалар соратып ала, тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча юридик зат җитәкчесе һәм/яки хезмәткәрләре, хосусый эшмәкәр белән әңгәмәләр үткәрә (күчмә тикшерү документар тикшерүдән соң үткәрелгән очракта, күчмә тикшерү үткәрелгәндә юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән документар тикшерү барышында тапшырылган документлар һәм (яки) мәгълүматларны тапшыруны таләп итү тыела);

5) тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча тапшырылган документларны, материалларны һәм аңлатмаларны анализлый һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозуларның булуы (булмавы) турында карар кабул итә;

6) закон бозу фактлары ачыкланганда:

а) закон бозу фактларын раслаган документлар (алга таба – раслау документлары) күчермәләрен билгеләнгән тәртиптә әзерли һәм раслый;

б) халыкны эш белән тәэмин итү турында закон бозу фактлары хакында мәгълүматларны тикшерү акты проектына кертә, раслау документлары күчермәләре белән;

7) үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләрне учетка алу журналына (юридик затның, хосусый эшмәкәрнең мондый журналы булганда) Министрлык атамасы, тикшерү үткәрүне башлау һәм төгәлләү даталары, аны үткәрү вакыты, хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм тикшерү предметы, ачыкланган закон бозу фактлары һәм бирелгән күрсәтмәләр турында мәгълүматлардан торган, тикшерүне үткәргән вазыйфаи зат яки вазыйфаи затлар фамилияләрен, исемнәрен, атасының исемнәрен һәм вазыйфаларын күрсәтеп, аның яки аларның имзалары белән, язу кертә;

8) эш бирүче тикшерүләрне учетка алу журналына ия булмаганда, тикшерү акты проектына тиешле язу кертә;

9) тикшерү акты проектын (тикшерү актының типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган) әзерли, аны тикшерү үткәрелгәндә юридик зат җитәкчесе, хосусый эшмәкәр тарафыннан тапшырылган документлар күчермәләре һәм исемлек (алга таба кушымталар) янына куя һәм тикшерү акты проектын тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә тапшыра;

башкару срогы: турыдан-туры тикшерү тәгәлләнгәннән соң;

10) 2 нөсхәдә тикшерү актына кул куя;

башкару срогы: турыдан-туры акт төзелгәннән соң;

11) тикшерү актының бер нөсхәсен, кушымталары күчермәләре белән, юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә (тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында имза салдырып) тапшыра яки тикшерелүче зат электрон рәвештә хезмәттәшлеккә ризалык биргән очракта, тикшерү актының бер нөсхәсен, кушымталары күчермәләре белән, әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы салынган электрон документ рәвешендә юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрә (әлеге актны тутырган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә тикшерелүче затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин иткән ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган булып санала);

башкару срогы: турыдан-туры актка кул куелганнан соң;

12) юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, хосусый эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат танышу яки танышудан баш тарту турында имза куюдан баш тарткан очракта – тикшерү актын почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) җибәрүне тәэмин итә, уведомление Министрлык делосында сакланылучы тикшерү акты нөсхәсе янына куела;

башкару срогы: турыдан-туры актка кул куелганнан соң;

13) тикшерү актының икенче нөсхәсенә тиешле язу кертә, аны почта аша заказлы хат белән тапшыру турында уведомление һәм (яки) тикшерү актын алуны раслаган башка документ янына куя;

башкару срогы: турыдан-туры тикшерү актын почта аша заказлы хат белән җибәргәннән соң;

14) тикшерү акты янына, юридик зат җитәкчесе, хосусый эшмәкәр тикшерү акты эчтәлеге белән килешмәгән очракта, юридик зат җитәкчесенең, хосусый эшмәкәрнең язмача каршы килүләрен (булганда) куя;

башкару срогы: турыдан-туры юридик зат җитәкчесе, хосусый эшмәкәрнең каршы килүләрен алганнан соң;

15) тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнар бозу фактлары булганда, бу Административ регламентның 5.47 пунктында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл кыла.

5.18. Планлы күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча җаваплы эш башкаручы тарафыннан карар кабул итүнең критерие булып тикшерү вакытында тапшырылган документлар һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнарга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.19. “Планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнар бозу фактларының булуы яки законнар бозу фактларының булмавы теркәлгән тикшерү акты тора.

5.20. “Планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.21. Планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү хосусый эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең юридик зат җитәкчесе яки башка вазыйфаи затының урында булмавы сәбәпле, яки юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан эшчәнлекнең фактта алып барылмавы сәбәпле, яисә хосусый эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесе яки башка вазыйфаи затының тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китергән гамәлләренә бәйле рәвештә, мөмкин булмаган очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты, тикшерүне үткәреп булмау сәбәпләрен күрсәтеп, тиешле тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзи. Бу очракта Министрлык тиешле тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавы турында акт төзелгәннән соң өч ай эчендә, планлы тикшерүне планлы тикшерүләрнең еллык планына кертмичә һәм юридик затка, хосусый эшмәкәргә алдан хәбәр итеп тормыйча гына, мондый юридик затка, хосусый эшмәкәргә карата планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итүгә хокуклы.

## “ПЛАНЛЫ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ” АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.22. “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып тиешле юридик затны, хосусый эшмәкәрне еллык Планга кертү һәм “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү”

административ процедураның төгәлләнүе тора. План Министрлыкның интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

5.23. Җаваплы эш башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне хәл кыла:

1) Министрлык карамагындагы юридик зат, хосусый эшмәкәр материалларын һәм документларын алдагы тикшерүләр актларын, административ хокук бозулар турында эшләрне карап тикшерү материалларын һәм билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу буенча әлеге юридик затка, хосусый эшмәкәргә карата хәл ителгән күзәтчелек һәм контрольлек чаралары нәтиҗәләре турында башка документларны өйрәнә;

2) юридик зат, хосусый эшмәкәр исеменә, Министрлык карамагындагы документлардагы мәгълүматларның дөреслеге нигезле шикләнүләр тудырганда яки бу мәгълүматлар инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнарның мәҗбүри таләпләренең юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан үтәлүен бәяләү мөмкинлеге бирмәгән очракта, документар тикшерү үткәрү барышында карап тикшерү өчен кирәкле башка документларны тапшыру таләбе белән запрос, запроска тикшерү үткәрү турында боерык (распоряжение) күчермәсе (мөһер салынган) белән, җибәрә (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән), яки электрон почта аша);

3) юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән (кирәк булганда) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүматлар соратып ала (фәкать тикшерү үткәрү турында распоряжение яки боерык кабул ителгәннән соң); шул ук вакытта юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән документар тикшерү предметына кермәүче мәгълүматларны һәм документларны, шулай ук башка дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органнарыннан алып булган мәгълүматлар һәм документларны таләп итүгә хокуклы була алмый;

4) юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан тапшырылган, элегрәк тапшырылган документларның дөреслеген раслаган аңлатмалар һәм документларны карап тикшерә; запроста күрсәтелгән документлар мөһер (булганда) белән расланган һәм хосусый эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты имзасы белән расланган күчермәләр рәвешендә тапшырыла; юридик зат, хосусый эшмәкәр запроста күрсәтелгән документларны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә тапшыруга хокуклы;

5) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен хосусый эшмәкәрне, аның вәкаләтле вәкилен ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган документлар яки мәгълүматлар белән таныштыра;

6) юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан түбәндәге нигезләмәләрнең үтәлүен тикшерү максатыннан чыгып, юридик зат, хосусый эшмәкәрдән алынган

материалларны һәм документларын өйрәнү нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш ураннарын квоталау өлкәсендә закон бозуларның булуы (булмавы) турында карар кабул итә:

а) инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары санының инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнар таләпләренә туры килүе;

б) фактта эшләүче инвалидлар санының инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарының тиешле санына туры килүен;

в) юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган билгеләнгән срокларда инвалидларны һөнәри реабилитацияләү һәм аларга эшкә урнашуга ярдәм итү эшчәнлеген хәл кылу өчен кирәкле мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген;

г) юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган билгеләнгән срокта инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген;

7) тикшерү акты проектын әзерли, аның янына кушымталарны куя, тикшерү акты проектын тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә тапшыра;

башкару срогы: турыдан-туры тикшерү тәгалләнгәннән соң.

8) ике нөсхәдә тикшерү актына кул куя;

башкару срогы: турыдан-туры актны рәсмиләштергәннән соң;

9) тикшерү актының бер нөсхәсен, кушымталары күчермәләре белән, юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә (тикшерү акты белән танышу яки танышудан баш тарту турында имза салдырып) тапшыра яки тикшерелүче зат электрон рәвештә хезмәттәшлеккә ризалык биргән очракта, тикшерү актының бер нөсхәсен, кушымталары күчермәләре белән, әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы салынган электрон документ рәвешендә юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә җибәрә (әлеге актны тутырган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә тикшерелүче затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин иткән ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган булып санала);

башкару срогы: турыдан-туры актка кул куелганнан соң;

10) юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, хосусый эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче

зат танышу яки танышудан баш тарту турында имза куюдан баш тарткан очракта – тикшерү актын почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) җибәрүне тәэмин итә, уведомление Министрлык делосында саклануычы тикшерү акты нөсхәсе янына куела;

башкару срогы: турыдан-туры актка кул куелганнан соң;

11) тикшерү акты янына, юридик зат җитәкчесе, хосусый эшмәкәр тикшерү акты эчтәлеге белән килешмәгән очракта, юридик зат җитәкчесенең, хосусый эшмәкәрнең язмача каршы килүләрен (булганда) куя;

башкару срогы: турыдан-туры почта аша тикшерү акты җибәрелгәннән соң һәм (яки) юридик зат җитәкчесе, хосусый эшмәкәрнең каршы килүләрен алганнан соң;

12) тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнар бозу фактлары булганда, бу Административ регламентның 5.47 пунктында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл кыла.

5.24. Тапшырылган аңлатмалар һәм документлар карап тикшерелгәннән соң яки аңлатмалар булмаганда мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре билгеләнгән очракта һәм күчмә тикшерү үткәрү өчен төпле нигез булганда, җаваплы эш башкаручы күчмә тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли, ул министрга (министр урынбасарына) имза салуга җибәрелә. Күчмә тикшерү үткәрү турында карарны министр (министр урынбасары) кабул итә. Күчмә тикшерү үткәрелгәндә юридик заттан, хосусый эшмәкәрдән документар тикшерү барышында тапшырылган документлар һәм (яки) мәгълүматларны тапшыруны таләп итү тыела.

5.25. Планлы документар тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча җаваплы эш башкаручы тарафыннан карар кабул итүнең критерие булып тикшерү вакытында тапшырылган документлар һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнарга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.26. “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнар бозу фактларының булуы яки законнар бозу фактларының булмавы теркәлгән тикшерү акты тора.

5.27. “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

“Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башкару срогы – бу Административ регламентның 2.1 пункты нигезендә.

## "ПЛАННАН ТЫШ КҮЧМӘ ҺӘМ ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮНЕ ӘЗЕРЛӘҮ" АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.28. "Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү" административ процедурасын башлап җибәрүгә нигезләр булып бу Административ регламентның 2.17 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.29. Министр (министр урынбасары) тикшерү үткәрү турында карар кабул итә һәм Министрлыкның социаль яктан якланылмаган категорияләре өчен эш урыннарын булдыру бүлеге начальнигына тикшерү үткәрергә куша;

башкару срогы: планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканнан соң бер эш көне эчендә.

5.30. Министрлыкның социаль яктан якланылмаган категорияләре өчен эш урыннарын булдыру бүлеге начальнигы, юридик затка, хосусый эшмәкәргә тикшерү үткәрү өчен, Министрлыкның социаль яктан якланылмаган категорияләре өчен эш урыннарын булдыру бүлегенең вазыйфаи затлары арасыннан җаваплы эш башкаручыны (җаваплы эш башкаручылар) (алга таба – җаваплы эш башкаручы) билгели;

башкару срогы: планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләрнең килеп чыгу көненнән соң бер эш көне эчендә.

5.31. Җаваплы эш башкаруы түбәндәге административ гамәлләрне хәл кыла:

1) бу Административ регламентның 2.17 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыккан очракта – бу Административ регламентның 2.18-2.23 пунктларында бәян ителгән таләпләр нигезендә гамәлләр кыла:

а) мөрәҗәгать иткән затны билгеләүгә карата тиешле чаралар күрә;

б) моңа кадәр алынган мондый мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар нәтиҗәләрен, мәгълүматларны, шулай ук тиешле юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә карата моңа кадәр үткәрелгән контрольлек чаралары нәтиҗәләрен карап тикшерә;

в) алынган мәгълүматларга башлангыч тикшерү үткәрә;

г) кирәк булганда, юридик зат, хосусый эшмәкәр белән хезмәттәшлек итмичә генә һәм әлеге затларга мәгълүматлар тапшыру һәм Министрлык таләпләрен үтәү бурычларын йөкләмичә генә контрольлек чаралары үткәрә.

д) бу Административ регламентның 2.17 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү билгеләү турында нигезле күрсәтмә әзерли;

2) бу Административ регламентның 5.12 пунктында күрсәтелгән таләпләрне үтәп, тикшерү үткәрү турында боерык (распоряжение) проекты әзерли (тикшерү үткәрү турында боерыкның (распоряжение) типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы нигезендә расланган);

башкару срогы: тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) карары кабул ителгәннән соң күп дигәндә ике эш көне;

3) министр (министр урынбасары) тарафыннан тикшерү үткәрү турында боерыкның (распоряжение) имзалануын тәэмин итә;

башкару срогы: күп дигәндә ике эш көне;

4) бу Административ регламентның 2.17 пунктындагы 2 пунктчасында “а” һәм “б” пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча күчмә тикшерүгә әзерләнгәндә:

– юридик затның, хосусый эшмәкәрнең эшчәнлеген хәл итү урыны буенча прокуратура органына планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза (планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган) әзерләп тапшыра яки, тикшерү үткәрү турында боерык (распоряжение) күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булып хезмәт иткән мәгълүматлардан торган документлар белән, гаризаны почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә;

башкару срогы: тикшерү үткәрү турында боерыкка (распоряжение) кул куелган көнне;

планнан тыш күмә тикшерү үткәрүне килештерү турында прокуратура органыннан карар ала;

5.7. Юридик зат җитәкчесенә, хосусый эшмәкәргә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында уведомление җибәрә, бу Административ регламентның 2.17 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланып, юридик затның, хосусый эшмәкәрнең электрон почта адресына (юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында мондый адрес булганда яки электрон почта адресы моңа кадәр юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан Министрлыкка тапшырылганда) электрон документ рәвешендә уведомлениене җибәрә;

башкару срогы: юридик затка, хосусый эшмәкәргә уведомление җибәрү – тикшерү башланганчы кимендә егерме дүрт сәгать кала.

5.32. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүгә әзерләнү буенча карар кабул итүнең критерие

булып бу Административ регламентның 2.17 пунктында күрсәтелгән очракларның булуы тора.

5.33. “Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып тора:

тикшерү үткәрү өчен җаваплы эш башкаручыны билгеләү;

тикшерү үткәрү турында боерык (распоряжение);

юридик зат, хосусый эшмәкәр исеменә тикшерү үткәрү турында уведомление җибәрү.

5.34. “Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасы башкару нәтиҗәсен теркәү бу Административ регламентның 5.33 пунктында, эш материалларында күрсәтелгән уведомлениеләр, боерык (распоряжение) күчермәләрен учетка алу һәм саклау, шулай ук, Министрлыкта делопроизводство алып бару кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә әлеге документларны электрон рәвештә аерым саклау юлы белән хәл ителә.

“ПЛАННАН ТЫШ КҮЧМӘ ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ“ АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.35. “Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып бу Административ регламентның 2.17 пунктында күрсәтелгән очракларның килеп чыгуы, бу эш бирүченең эшчәнлеген хәл кылу урыны буенча прокуратура органы белән тикшерү үткәрүне килештерү, “Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасының төгәлләнүе тора.

5.36. Җаваплы эш башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне хәл кыла.

1) бу Административ регламентның 5.17 пунктындагы 1 пунктчасында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл итә;

2) тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле документлардагы мәгълүматларны өйрәнә һәм нигезләргә бәйле рәвештә тикшерә:

а) ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуны һәм (яки) Татарстан Республикасы хокукый актларында билгеләнгән таләпләрне бозуны юкка чыгару турында моңа кадәр бирелгән күрсәтмәнең эш бирүче тарафыннан үтәлүен (планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне бозуны юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү срогының чыгуы торса, мондый тикшерүнең предметы булып фәкать Министрлык тарафыннан бирелгән күрсәтмәне үтәү генә торырга мөмкин);

б) гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүне кисәтү, китерелгән мондый зыянның аянычлы нәтиҗәләрен юкка чыгару буенча чаралар үткәрелүен;

в) Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрдән, юридик затлардан алынган мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларда гражданнарның хокукларын бозуы турында бәян ителгән фактларны (билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тарту);

г) прокуратура органнарына алынган материалларда һәм мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән фактларны;

3) бу Административ регламентның 5.17 пунктындагы 4.14 пунктчаларында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл кыла;

4) тикшерү акты күчермәсен планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына, имзаланганнан соң 5 эш көне эчендә, җибәрә;

5) тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозу фактлары булганда, бу Административ регламентның 5.47 пунктында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл кыла;

5.37. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча карар кабул итү критерие булып тикшерү вакытында тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнарга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.38. “Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедураның нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозуларның булуы яки булмавы теркәлгән тикшерү акты тора.

5.39. “Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

“Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү срогы – бу Административ регламентның 2.11 пункты нигезендә.

5.40. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү хосусый эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесе яки башка вазыйфаи затының урында булмавы сәбәпле, яки юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан эшчәнлекнең фактта алып барылмавы сәбәпле, яисә хосусый эшмәкәрнең, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесе яки башка вазыйфаи затының тикшерү үткәрүнең мөмкин булмавына китергән гамәлләренә бәйле рәвештә, мөмкин булмаган очракта, Министрлыкның вазыйфаи заты бу Административ регламентның 5.21 пункты нигезендә гамәлләр кыла.

## “ПЛАННАН ТЫШ ДОКУМЕНТАР ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ” АДМИНИСТРАТИВ ПРОЦЕДУРАСЫ

5.41. “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып бу Административ регламентның 2.17 пунктында күрсәтелгән очракларның килеп чыгуы һәм “Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасының тәгалләнүе тора.

5.42. Җаваплы эш башкаручы түбәндәге административ гамәлләрне хәл кыла.

1) бу Административ регламентның 5.36 пунктындагы 2 пунктчасында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл итә;

2) бу Административ регламентның 5.23 пунктындагы 2, 5-11 пунктчаларында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл кыла;

3) тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозу фактлары булганда, бу Административ регламентның 5.47 пунктында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл кыла.

5.43. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планнан тыш документар тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча карар кабул итү критерие булып тикшерү вакытында тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнарга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.44. “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедураның нәтиҗәсе булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозуларның булуы яки булмавы теркәлгән тикшерү акты тора.

5.45. “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башкару нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

“Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү срогы – бу Административ регламентның 2.11 пункты нигезендә.

## ТИКШЕРҮ АКТЫНДА ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ ИНВАЛИДЛАРНЫ ЭШКӘ АЛУ ӨЧЕН ЭШ УРЫННАРЫ КВОТАСЫН БУЛДЫРУ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЗАКОННАР БОЗЫЛУ ФАКТЛАРЫ БУЛГАНДА, ТИКШЕРҮ ҮТКӘРҮ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ЧАРАЛАР КҮРҮ

5.46. “Тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнар бозылу фактлары булганда, тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү” административ процедурасын башлау өчен нигез булып халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законнар бозылуның тикшерү актында булган фактлары тора.

5.47. Җаваплы эш башкаручы түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) башкара:

- халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә юл куелган законнар бозуны юкка чыгару турында һәм (яки) кешеләр гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерүне кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда күздә тотылган башка чаралар үткәрү турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмәне (типовой формасы бу Административ регламентка №5 кушымтада китерелгән) әзерләп тапшыра;

башкару срогы: бер үк вакытта тикшерү акты тутырып, турыдан-туры тикшерү тәгәлләнгәннән соң;

2) юридик зат җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, хосусый эшмәкәргә, аның вәкаләтле вәкиленә, имза салдырып, бу Административ регламентның 5.17 пунктындагы 11, 12 пунктчалары нигезендә, имза салдырып, күрсәтмә бирә;

3) ачыкланган бозуларны юкка чыгару, аларны кисәтү, гражданнар гомере, сәламәтлегенә ихтимал зыянны булдырмый калу, шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә;

башкару срогы: әлеге очракларны кисәтү, булдырмый калу – бозулар ачыкланганнан соң турыдан-туры; бозуларны юкка чыгаруга контрольлек итү – юкка чыгару.

4) тикшерү үткәргәндә эш бирүче тарафыннан билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу бурычлары үтәлмәүнең ачыклануы турында хезмәт язуын, тикшерү актының расланган күчермәсе, тикшерү акты янына куелган материаллар күчермәләре, эш бирүчене тикшерү акты белән таныштыруны раслаган документлар һәм тикшерү үткәргәндә ачыкланган бозуларны раслаган башка материаллар белән, Министрлыкның юридик бүлегенә җибәрә (тапшыра);

башкару срогы: турыдан-туры административ хокук бозу ачыкланганнан соң.

5.48. Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты түбәндәге административ гамәлләрне башкара:

1)тапшырылган материалларны РФ КоАП 5.42 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу вакыйгаларының булу-булмавын күрсәткән тулы мәгълүматлардан тору предметына карап тикшерә;

2) РФ КоАП 5.42 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу вакыйгасының булу-булмавына күрсәткән тулы мәгълүматлар булганда, үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылачак юридик зат җитәкчесенә, хосусый эшмәкәргә административ хокук бозу вакыйгасының булуы, административ хокук бозу турында беркетмәне төзү датасы һәм урыны турында извещение җибәрүне (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яисә электрон почта аша) тәэмин итә;

башкару срогы: Министрлыкның социаль яктан якланылмаган категорияләре өчен эш урыннарын булдыру бүлеге бу Административ регламентның 5.47 пунктындагы 4 пунктчасында билгеләнгән документлар һәм материалларны тапшырганнан соң күп дигәндә өч эш көне эчендә;

3) үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылачак эшмәкәргә яки юридик зат җитәкчесенә җибәрелгән извещениедә күрсәтелгән көнне, административ хокук бозу турында беркетмә төзү датасы буларак билгеләнгән көнне, килеп туган хәлне өстәмә ачыклау яки эшмәкәр яисә юридик зат җитәкчесе турында мәгълүматларны аныклау таләп ителмәгән очракта, РФ КоАП 5.42 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә төзи. Административ хокук бозу турында беркетмә төзегәндә, үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган эшмәкәргә яки юридик зат җитәкчесенә, шулай ук кузгатылган эш буенча башка катнашучыларга бу РФ КоАПта күздә тотылган үзләренең хокуклары һәм бурычлары аңлатыла. Бу хакта беркетмәгә язып куела. Үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган эшмәкәргә яки юридик зат җитәкчесенә административ хокук бозу турында беркетмә белән танышу мөмкинлеге бирелергә тиеш. Әлеге затлар беркетмәнең эчтәлеге буенча үзләренең аңлатмаларын һәм искәртүләрен (беркетмә янына куела) тапшыруга хокуклы, эшмәкәр яки юридик зат җитәкчесе административ хокук бозу турында беркетмәгә кул куюдан баш тартканда, беркетмәгә тиешенчә язып куя. Административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсе үзенә карата беркетмә төзегән затка кичекмәстән тапшырыла.

Үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган эшмәкәр яки юридик зат җитәкчесе килмәгән очракта, аларга билгеләнгән тәртиптә хәбәр ителсә, административ хокук бозу турында беркетмә алар югында төзелә;

4) административ хокук бозу турында беркетмә төзүгә килмәгән очракта, эшмәкәргә яки юридик зат җитәкчесенә 3 көн эчендә административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсен җибәрүне (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яисә электрон почта аша) тәэмин итә;

башкару срогы: беркетмә төзелгәннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча;

5) административ хокук бозу турында беркетмәне, административ хокук бозу турында эшне карап тикшерү өчен, гомуми юрисдикция судына җибәрүне (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) җибәрүне тәэмин итә;

башкару срогы: беркетмә төзелгәннән соң күп дигәндә өч тәүлек;

үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылган эшмәкәрдән яки юридик зат җитәкчесеннән административ хокук бозу турында эш карап тикшерүгә җибәрелгән гомуми юрисдикция судында билгеләнгән тәртиптә беркетмәгә каршы килүләр алынган очракта, административ хокук бозу турында беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртүләр җибәрүне тәэмин итә;

башкару срогы: административ хокук бозу турында беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртүләр алынганнан соң күп дигәндә өч эш көне;

7) административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсен тикшерү материаллары янына куя;

башкару срогы: административ хокук бозу турында беркетмәне (беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртүләр) гомуми юрисдикция судына җибәргәннән соң 1 эш көне эчендә;

5.49. Җаваплы эш башкаручы, планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелгән күрсәтмә эш бирүче тарафыннан ике айлык срокта үтәлмәгән очракта, күрсәтмәне үтәү срогы тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә, гаепле затларны РФ КоАП 19.5 статьясындагы 1 өлеше нигезендә административ җаваплылыкка тарту өчен нигезләрнең булуын раслаган материаллар һәм документлар белән, хезмәт язуын Министрлыкның юридик бүлегенә әзерләп җибәрә.

Башкару срогы: күрсәтмәне үтәү срогы тәмамланганнан соң 5 эш көне эчендә.

5.50.Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты, бу Административ регламентның 5.49 пункты нигезендә материаллар алынгач, бу Административ регламентның 5.48 пунктында билгеләнгән шундый ук административ гамәлләрне кыла.

5.51. Җаваплы эш башкаручы  түбәндәгеләр турында Министрлыкка юридик зат җитәкчесеннән, хосусый эшмәкәрдән алынган мәгълүматларга контрольлекне хәл итә:

тикшерүләр барышында ачыкланган инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә законнар бозуларны юкка чыгару;

халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә юл куелган закон бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү.

5.52. Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар кабул итү ягыннан карар кабул итүнең критерие булып, тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнар бозулар фактлары булганда, тикшерү актында урын алган халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнар бозулар фактлары тора.

5.53. "Тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнар бозулар фактлары булганда тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү" административ процедурасының нәтиҗәсе булып тора:

халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә юл куелган закон бозуларны юкка чыгару турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмә;

административ хокук бозу турында беркетмә.

5.54. "Тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә законнар бозулар фактлары булганда тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү" административ процедурасын башкаруның нәтиҗәсе тикшерү актында, тикшерүләрнең бердәм реестрында, Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

## 6. ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕ КОНТРОЛЬДӘ ТОТУНЫҢ ТӘРТИБЕ ҺӘМ ФОРМАЛАРЫ

6.1. Министрлык вазыйфаи затларның үз хезмәт бурычларын үтәвен контрольдә тота, вазыйфаи затларның тикшерүләр үткәрү барышында үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәү очракларының исәбен алып бара, эш урынында тиешле тикшерүләр үткәрә һәм Россия Федерациясе законына туры китереп, андый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Бу Административ регламентның үтәлеше министр тарафыннан контрольдә тотыла.

6.3. Министрлыкның вазыйфаи затларының бу Административ регламент нигезендә дәүләт күзәтчелеге һәм контрольлеге буенча гамәлләр эзлеклелеген үтәвенә, карарлар кабул итүенә агымдагы контрольлек министр урынбасары, Министрлыкның социаль яктан якланылмаган категорияләре өчен эш урыннарын булдыру бүлеге начальнигы һәм Министрлыкның юридик бүлеге начальнигы (административ җаваплылыкка тарту турында беркетмәләр төзү ягыннан) һәм Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан башкарыла.

6.4. Министрлыкның дәүләт функциясен үтәүгә агымдагы контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле хезмәткәрләре исемлеге, әлеге контрольне гамәлгә ашыруның тәртибе һәм ешлыгы Министрлык актлары белән гамәлгә кертелә. Министрлык хезмәткәрләренең агымдагы контрольне башкару вәкаләтләре Министрлыкның

структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазыйфаларына кагылышлы инструкцияләрдә билгеләнә.

6.5. Агымдагы контроль бу Административ регламентның нигезләмәләре һәм дәүләт функциясен үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче бүтән норматив-хокукый актлар үтәлүне тикшерүләр үткәрү юлы белән башкарыла. Тикшерүләр үткәрүнең тулылыгына һәм сыйфатына агымдагы контроль даими рәвештә алып барыла һәм мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылуны тикшерүне, ачыклауны һәм билгеләүне, мондый закон бозуларны бетерү турында карарлар кабул итүне үз эченә ала.

6.6. Дәүләт функциясен үтәүгә контрольлек планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне үз эченә ала.

Дәүләт функциясен үтәүнең тулылыгы һәм сыйфатына планлы тикшерүләр Министрлыкның агымдагы елга еллык эш планы нигезендә үткәрелә. План лы тикшерүләр әлеге планга, Бүлек начальниклары белән килештереп, министрның күзәтчелек һәм контрольлек мәсьәләләре белән шөгыльләнүче урынбасары тарафыннан кертелә.

Планнан тыш тикшерүләр элегрәк ачыкланган закон бозуларның бетерелүен тикшерүгә бәйле рәвештә, шулай ук үз вазыйфаи бурычларын үтәгәндә Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр нигезендә үткәрелә.

6.7. Министрлыкның дәүләт функциясен үтәүгә җаваплы вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә дәүләт функциясен, хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәүләре, хокукка каршы гамәлләр кылган  (гамәл кылмау) өчен Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен башкару барышында кабул ителгән карарларына һәм күрелгән гамәлләренә (гамәл кылмау) карата дисциплинар җаваплылык чикләре аларның вазыйфаи регламентлары нигезендә билгеләнә.

Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында, андый чаралар күрелгән көннән башлап ун көн эчендә, хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган эш бирүчегә Министрлык язмача хәбәр итәргә тиеш.

6.8. Дәүләт функциясен үтәүгә гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольлек берләшмәләр һәм оешмаларның уставлары нигезендә хәл ителә. Министрлык үзенә билгеләнгән компетенциясе чикләрендә гражданнарга, иҗтимагый оешмаларга һәм башка оешмаларга  халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә иҗтимагый контрольлекне хәл кылуга ярдәм итә. Министрлыкка тапшырылган дәүләт функциясен үтәү буенча иҗтимагый контрольлек нәтиҗәләре Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри төстә карап тикшерелергә тиеш.

## 7. МИНИСТРЛЫКНЫҢ, ШУЛАЙ УК АНЫҢ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ КАРАРЛАРЫНА, ГАМӘЛЛӘРЕНӘ (ГАМӘЛ КЫЛМАУЛАРЫНА) СУДКА

## КАДӘР (СУДТАН ТЫШ) ШИКАЯТЬ БЕЛДЕРҮ ТӘРТИБЕ

7.1. Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле, кызыксынулы башка затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының тикшерү үткәргәндәге, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә урнаштыру вакытында үзләренең хокуклары бозылуга китергән карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче язмача кәгазьдә яки электрон рәвештә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә, шикаятен почта аша яки Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге сайтыннан (**http://mtsz.tatarstan.ru**) файдаланып яисә Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы (**http://uslugi.tatar.ru**) аша җибәрергә, шулай ук шикаятен Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә бирергә хокуклы.

7.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы булып Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышында кабул иткән яки башкарган карарлары яки гамәлләре (гамәл кылмаулары) тора.

7.3. Шикаятьне карап тикшерүне туктатып тору яки аны карап тикшерүдән баш тарту өчен нигезләр күздә тотылмаган. Министрлыкның яки вәкаләтләренә тәңгәл рәвештә вазыйфаи затка кергән шикаятьнең карап тикшерелүе мәҗбүри.

7.4. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми яисә анда куелган сорауларга тәфсилле җавап бирелми:

- әгәр шикаятьтә шикаятьне җибәргән гариза бирүченең фамилиясе (юридик затның атамасы) яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон адрес) күрсәтелмәгән булса;

- әгәр шикаятькә сүгенү яисә мыскыллау сүзләре, вазыйфаи затның шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янаулар кергән булса (Министрлыкның вазыйфаи заты шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә үз хокукларыннан явызларча файдаланырга ярамау турында хәбәр итәргә хокуклы);

- әгәр язмача шикаятьнең тексты укырлык булмаса (аның фамилиясе һәм почта адресы (электрон адресы) укырлык булган очракта, шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә, шикаять теркәлгән көннән башлап 7 көн эчендә бу хакта хәбәр ителә);

- әгәр шикаятьтә элегрәк җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә берничә тапкыр язмача тәфсилле җаваплар бирелгән сорау булса, һәм бу очракта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелмәсә (министр, вазыйфаи зат яисә шуңа вәкаләтле зат чираттагы шикаятьнең нигезсезлеге турында һәм әлеге мәсьәлә буенча гариза бирүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы (әлеге шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр Министрлыкка яки шул бер үк вазыйфаи затка

җибәрелгән очракта); шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә язышуны туктату турындагы әлеге карар хакында хәбәр ителә).

Әгәр шикаятьтә әзерләнүче, кылынучы яки кылынган законга каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар булса, шикаять, вәкаләтенә туры китереп, дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына карата белдерелүче шикаять, теркәлгән көненнән башлап җиде көн эчендә, әлеге суд карарына карата шикаять белдерүнең тәртибе аңлатылып, гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Шикаятьтә куелган сорауга тәфсилле җавапны дәүләт сере яки федераль закон белән сакланучы башка сер булып торган мәгълүматларны таратмыйча бирү мөмкин булмаган очракта, шикаятьне җибәргән гариза бирүчегә, әлеге мәгълүматларны таратырга ярамауга бәйле рәвештә, анда куелган сорауга тәфсилле җавап бирүнең мөмкин булмавы турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә куелган сорауларга тәфсилле җавап бирү мөмкин булмауның сәбәпләре алга таба бетерелгән очракта, гариза бирүче шикаятен Министрлыкка яки аның вазыйфаи затына кабат җибәрергә хокуклы.

7.5. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлау өчен нигез булып гариза бирүчедән (гариза бирүченең вәкаләтле вәкиленнән) шәхсән, яки почта аша хат рәвешендә, яки E-mail:mtsz@tatar.ru электрон адресына яки Министрлыкның рәсми сайты (**http://mtsz.tatarstan.ru**) аша электрон документ рәвешендә Министрлыкка мөрәҗәгать (шикаять) керү тора.

7.6. Мөрәҗәгать итүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алуга хокуклы. Андый төрдәге мәгълүматны һәм документларны алу өчен, гариза бирүчеләр Министрлык адресына язмача яки электрон рәвештә бу хакта рәсми мөрәҗәгать җибәрергә тиешләр. Министрлыкның вазыйфаи затлары, әгәр мәгълүматка Россия Федерациясе законы белән билгеләнгән чикләүләр булмаса, соралучы мәгълүматларны һәм документларны рәсми мөрәҗәгать теркәлгән көннән башлап 30 көн эчендә гариза бирүчегә бирергә тиеш.

7.7. Министрлыкның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять министрга җибәрелергә мөмкин. Министрлыкның һәм министрның гамәлләренә (гамәл кылмауларына), карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.8. Шикаятьләр Министрлык тарафыннан алар теркәлгән көннән башлап 30 көн эчендә карап тикшерелә.

7.9. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүнең нәтиҗәләре булып тора:

- дәүләт күзәтчелеген һәм контролен тормышка ашыру барышында кылынган

гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (башкарылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, ә тәгаен:

эш урынындагы тикшерү барышында вазыйфаи затның (вазыйфаи затларының) үз хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, аңа (аларга) карата Россия Федерациясе законына туры китереп чаралар күрү;

Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга андый чаралар күрелгән көннән башлап 10 көн эчендә язмача хәбәр бирү;

- дәүләт күзәтчелеген һәм контролен тормышка ашыру барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (башкарылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндермәү (мондый карарны дәлилле нигезләп, юридик затка, шәхси эшмәкәргә язмача хәбәр җибәрү юлы белән).

Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итү буенча дәүләт функцияләрен башкару буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламентына №1 кушымта

Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре турында мәгълүматлар

| Учреждение атамасы | Адресы | Телефоны |
|---|---|---|
| “Казан ш.халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420034, Казан ш., Декабристлар ур., 81 й., корп. А | (8-843) 562-48-33 |
| “Казан ш.халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ Совет районы буенча филиалы | 420029, Казан ш., Журналистлар ур., 13а й. | (8-843) 273-85-03 |
| “Авиатөзелеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420085, Казан ш., 1нче Муром ур., 33а й. | (8-843) 537-86-02 |
| “Вахитов районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420059, Казан ш., Павлюхин ур., 102 й. | (8-843) 277-52-93 |
| “Киров районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420032, Казан ш.,. Слободская ур., 23 й. | (8-843) 554-77-36 |
| “Мәскәү районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420039, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. | (8-843) 564-58-72 |
| “Яңа Савин районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420044, Казан ш., Ибраһимов ур.,41 й. | (8-843) 560-26-95 |
| “Идел буе районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420101, Казан ш., Бертуган Касыймовлар ур., | (8-843) 224-86-66 |

| | | |
|---|---|---|
| | 22/7 й. | |
| “Азнакай ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423330, Азнакай ш., Төзүчеләр ур., 10 й. | (8-85592) 7-57-00 |
| “Әлмәт ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423450,Әлмәт ш., Герцен ур.,86а й. | (8-8553) 32-34-99 |
| “Баулы ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423930, Баулы ш., Энгельс ур., 56 й. | (8-85569) 5-62-29 |
| “Бөгелмә ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423230, Бөгелмә ш.,. Октябрь ур., 15 й. | (8-85594) 4-17-60 |
| “Буа ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422430, Буа ш., Р.Люксембург ур., 157/1 й. | (8-84374) 3-35-89 |
| ГКУ «Центр занятости населения г. Елабуги» | 423600, Алабуга ш.,. Спас ур., 5 й. | (8-85557) 7-58-58 |
| “Зәй ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423520, Зәй ш., Нефтьчеләр ур., 37б й. | (8-85558) 7-15-43 |
| “Яшел Үзән ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422550, Яшел Үзән ш., Татарстан ур.,1 й. | (8-84371) 5-64-90 |
| “Лениногорск ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423250, Лениногорск ш., Гагарин ур.,51 й. | (8-85595) 5-59-70 |
| “Чаллы ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423831,Чаллы ш., Сөембикә пр., 47 й. | (8-8552) 52-42-68 |
| “Чаллы ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ Тукай районы буенча филиалы | 423831, Чаллы ш., Яңа шәһәр, Сөембикә пр., 47 (43/20) й. | (8-8552) 52-42-68, 52-97-06 |
| “Түбән Кама ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423570, Түбән Кама ш., Бызов ур., 20а й. | (8-8555) 42-40-79 |
| “Нурлат ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423040, Нурлат ш., Хәмәдиев ур.,19 й. | (8-84345) 2-46-32 |
| “Чистай ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422980, Чистай ш., К.Маркс пр., 35 й. | (8-84342) 5-13-34 |
| “Аксубай районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423060, Аксубай ш.т.б., Романов ур., 6 й. | (8-84344) 2-74-61 |
| “Актаныш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423740, Актаныш ав., . Ленин пр., 61 й. | (8-85552) 3-09-83 |
| “Алексеевск районы | 422900, Алексеевск р.б., | (8-84341) |

| | | |
|---|---|---|
| халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | Ленин ур., 87 й. | 2-59-00 |
| “Әлки районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422870, Әлки районы, . Базарлы Матак ав., Совет ур,, 8 й. | (8-84346) 2-15-21 |
| “Апас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422350, Апас ш.т.б., Шоссе ур., 5 й. | (8-84376) 2-12-15 |
| “Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422000, Арча ш.т.б.,. Банк ур., 6В й. | (8-84366) 3-29-33 |
| “Әтнә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422750, Олы Әтнә ав., Совет ур., 63 й. | (8-84369) 2-16-50 |
| “Балтач районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422250, Балтач ш.т.б., Совет ур., 16 й. | (8-84368) 2-52-34 |
| “Югары Ослан районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 1 й. | (8-84379) 2-24-28 |
| “Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422700, Биекату ав., Үзәк ур., 7а й. | (8-84365) 3-16-17 |
| “Чүпрәле районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422470, Иске Чүпрәле ав., Мәктәп ур., 16 й. | (8-84375) 2-24-51 |
| “Кайбыч районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422330, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7 й. | (8-84370) 2-10-06 |
| “Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422110, Кукмара бистәсе, Ворошилов ур., 44 й. | (8-84364) 2-67-54 |
| “Лаеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422610, Лаеш ш., Беренче Май ур., 16 й. | (8-84378) 2-49-31 |
| “Мамадыш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422190, Мамадыш ш., Муса Җәлил ур., 12 й. | (8-85563) 3-35-57 |
| “Менделеев районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423650, Менделеев ш., Фомин ур., 19 й. | (8-85549) 2-02-02 |
| “Менделеев районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ Әгерҗе районы буенча филиалы | 422230, Әгерҗе ш., Сәетов ур., 8а й. | (8-85551) 2-31-73, 2-29-84 |

| | | |
|---|---|---|
| “Минзәлә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423700, Минзәлә ш., Ленин ур., 78 й. | (8-85555) 3-23-80 |
| “Мөслим районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й. | (8-85556) 2-49-50 |
| “Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423119, Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 93 й. | (8-84348) 2-30-42 |
| “Питрәч районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422770, Питрәч ав.,. Совет ур., 34 й. | (8-84367) 3-04-84 |
| “Балык Бистәсе районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422650, Балык Бистәсе ш.т.б., Ленин ур., 48 й. | (8-84361) 2-21-81 |
| “Саба районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422060, Байлар Сабасы ш.т.б.,Тукай ур., 87 й. | (8-84362) 2-44-11 |
| “Сарман районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423350, Сарман ав., Ленин ур., 26 й. | (8-85559) 2-42-62 |
| “Спас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422840, Спас районы, . Болгар ш., Хирург Шеронов ур., 21 й. | (8-84347) 3-07-72 |
| “Тәтеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422370, Тәтеш ш., Ирек м., 45 й. | (8-84373) 2-63-29 |
| “Тәтеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ Кама Тамагы буенча филиалы | 422820, Кама Тамагы ш.т.б., К.Маркс ур., 2а й. | (8-84377) 2-14-67, 2-18-84 |
| “Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422080, Теләче ав., Ленин ур.,73 й. | (8-84360) 2-13-51 |
| “Чирмешән районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423100, Чирмешән ав., Титов ур., 5й. | (8-84396) 2-54-59 |
| “Ютазы районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423950, Урыссу ш.т.б.,, Пушкин ур., 38 й. | (8-5593) 2-60-16 |

Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итү буенча дәүләт функцияләрен башкару буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламентына №2 кушымта

Юридик затларга, хосусый эшмәкәрләргә карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| Мәҗбүри таләпләр исемлеге | Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив-хокукый акт | Тикшерү үткәргәндә юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр күрсәтергә тиешле документлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1.Юридик затлар, хосусый эшмәкәрләр (алга таба – эш бирүчеләр) билгеләнгән квоталар нигезендә, алар кертелгәннән соң бер ай эчендә, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары бүлеп бирүгә, кирәк булган очракта инвалидларга эш урыннары, махсус эш урынның минималь санын, | № 181-ФЗ Федераль законның 24 статьясындагы 1 пункты; № 60-ЗРТ ТР Законының 3, 6 статьялары ; Нигезләмәнең 3.1 пункты | Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары бүлеп бирү, кирәк булган очракта эш урыннарын булдыру турында юридик зат, хосусый эшмәкәр тарафыннан расланган боерык (распоряжение) күчермәсе;<br><br>Нигезләмәгә №3 кушымта нигезендәге форма буенча, халыкны эш белән тәэмин |

| | | |
|---|---|---|
| инвалидлар өчен резервтагы эш урыннары санын булдыруга бурычлы, шулай ук әлеге эш урыннары турында мәгълүматлардан торган локаль норматив актлар кабул итүгә бурычлы. | | итү үзәгенә юридик зат, х (уведомление |
| 2.Эш бирүчеләр инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләү программасы нигезендә инвалидларга хезмәт шартлары тудыруга бурычлы. | № 181-ФЗ Федераль законның 24 статьясындагы 2 пункты; № 60-ЗРТ ТР Законының 6 статьясы; Нигезләмәнең 3.1 пункты | Инвалидны индивидуаль махсус хезмә итеп алынг норматив акт |
| 3.Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә ай саен инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән буш эш урыннарының һәм вакантлы вазыйфаларның булуы турында ай саен мәгълүмат тапшыру, әлеге эш урыннары, инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүматлардан торган локаль норматив актлар турында мәгълүматларны кертеп | № 181-ФЗ Федераль законның 24 статьясындагы 3 пункты;<br>№ 1032-1 Россия Федерациясе Законының 25 статьясындагы 3 пункты;<br>№ 60-ЗРТ ТР Законының 3,6 статьялары;<br>Нигезләмәнең 3.2 пункты;<br>№ 60-ЗРТ ТР Законының 6 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты | Нигезләмәгә форма буенч итү үзәгенә юридик зат, х (уведомление |

| | | |
|---|---|---|
| 4. Инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү (билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тартуның булмавы) | № 60-ЗРТ ТР Законының 6 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты | Инвалидларн<br>билгеләнгән<br>бүлеп бирелі<br>турында юр<br>раслаган<br>күчермәсе;<br>билгеләнгән<br>эшкә алудан<br>раслаган кара |
| 5. Эш бирүчеләр тарафыннан, хезмәткәр эштән киткәннән соң ун көн эчендә, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә билгеләнгән квоталар кысаларында бүлеп бирелеп яки булдырылып, хәзер бушап калучы эш урыннары турында мәгълүмат тапшыру | № 60-ЗРТ ТР Законының 6 статьясындагы 2 өлешенең 2.1 пункты;<br>Нигезләмәнең 3.4 пункты | Нигезләмәгә<br>форма буенч<br>итү үзәгенә<br>юридик зат, х<br>(уведомление |
| 6. Эш бирүче тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә билгеләнгән квотаны үтәү (квотаны үтәү мөмкинлеге булмау) һәм инвалидларны эшкә алу өчен вакансияләр, эш бирүчеләрдә эшләүче инвалидлар саны турында мәгълүмат тапшыру | № 181-ФЗ Федераль законның 24 статьясы;<br>Нигезләмәнең 2.7, 2.14,3.2 пунктлары; | Халыкны эш<br>җибәрү тур<br>эшмәкәр ра<br>күчермәсе:<br>Нигезләмәгә<br>форма буенча<br>квотаны үтәү<br>Нигезләмәгә |

| | | |
|---|---|---|
| | | форма бує<br>булмау тур<br>Нигезләмә<br>форма буен |

Билгеләнгән квота чик
алуга, тикшерүләр үткәрү
күрсәтмәләр бирү һәм берке
күзәтчелек һәм контрольле
функцияләрен башкару буе
Хезмәт, халыкны эш белән т
министрлыгының админис
кушымта

Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, хосус
тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

| Тикшерү үткәрү өчен тапшырыла торган документ | Документ формасын билг |
|---|---|
| 1. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары бүлеп бирү, кирәк булган очракта эш урыннары булдыру турында юридик зат, хосусый эшмәкәр раслаган боерык (распоряжение) күчермәсе | |
| 2. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квота чикләрендә бүлеп бирелгән һәм (яки) булдырылган эш урыннарына инвалидны эшкә алу турында юридик зат, хосусый эшмәкәр раслаган боерык (распоряжение) күчермәсе | |
| 3. Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан баш тарту турында юридик зат, хосусый эшмәкәр раслаган карар | |

| | |
|---|---|
| күчермәсе | |
| 4.Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә түбәндәге мәгълүматларны җибәрү турында юридик зат, хосусый эшмәкәр раслаган хат (уведомление) күчермәсе:<br>- эш бирүчеләрдә эшләүче инвалидлар саны турында;<br>- квотаны үтәү мөмкинлеге булмауның объектив шартлары (сәбәпләре) турында;<br>- инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квота чикләрендә эш урыннары бүлеп бирү һәм (яки) булдыру турында;<br>-билгеләнгән квоталар чикләрендә бүлеп бирелеп яки булдырылып, хәзер бушап калучы эш урыннары турында | Нигезләмәгә №1 кушымта;<br>Нигезләмәгә №2 кушымта;<br>Нигезләмәгә №3 кушымта;<br>Нигезләмәгә №5 кушымта; |
| 5. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәегнә билгеләнгән квотаны үтәү һәм инвалидларны эшкә алу өчен вакансияләр турында мәгълүмат җибәрү хакында юридик зат, хосусый эшмәкәр раслаган хат (уведомление) күчермәсе | Нигезләмәгә №4 кушымта. |

Билгеләнгән квота чик
алуга, тикшерүләр үткәрү
күрсәтмәләр бирү һәм берке
күзәтчелек һәм контрольле
функцияләрен башкару буе
Хезмәт, халыкны эш белән т
министрлыгының админис
кушымта

Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри
бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итү бу
башкаруның блок-схемасы

| | |
|---|---|
| Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуны хәл кылуга планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрү | Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуны хәл кылуга планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрү |

Күчмә һәм документар тикшерүләр үткәрү планын әзерләү һәм раслау

Инвалидлар өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозулар турында мәгълүматлар алыну

Планлы күчмә тикшерү үткәрү турында боерыкны (распоряжение) раслау

Планлы документар тикшерү үткәрү турында боерыкны (распоряжение) раслау

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерыкны (распоряжение) раслау

Планнан ты тикшерү үткәрү тур боерыкны (распоряж раслау

Оешмага планлы күчмә тикшерү үткәрү турында хәбәр итү

Оешмага планлы документар тикшерү үткәрү турында хәбәр итү

Оешмага плантан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында хәбәр итү

Оешмага планн тыш докумен тикшерү үткәр турында хәб

Оешманың планлы документар тикшерү

Оешманы тыш доку

өчен кирәкле
материалларны
һәм документларны
тапшыруы турында
запрос (таләп) җибәрү

тикшеру

кирәкле матер
һәм докумен
тапшыруы т
запрос (тала

1

1

Тикшерү үткәрү

Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле хезмәткәрләр оешманың бу Административ регламентның №2 кушымтасында бәян ителгән мәҗбүри таләпләрне үтәвен тикшерә. Шул исәптән:

Оешманың халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә түбәндәге мәгълүматларның тапшырылуын:

инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота чикләрендә эш урыннарын бүлеп бирү (булдыру) турында;

инвалидларны эшкә алу (инвалидларны эшкә алу өчен

оешма тарафыннан бүлеп бирелгән (булдырылган)эш урыннары санының (шул исәптән махсус)инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон таләпләренә туры килүе);

оешманың инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квотаны үтәве (билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә урнаштыру өчен нигезсез баш тартуның булмавы);

оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә түбәндәге мәгълүматларны тапшыру:

билгеләнгән квоталар кысаларында бүлеп бирелеп яки булдырылып, хәзер бушап калучы эш урыннары турында;

инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында

↓

Тикшерү актын тутыру

↓ ↓

Бозулар ачыкланса | Бозулар ачыкланмаса

↓

Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты инвалидлар өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозу очрагы билгеләндә, шулай ук административ хокук бозу составы билгеләре булганда:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә төзи;

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.7 статьясында күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә төзи. Җаваплы эш башкаручы, ачыкланган бозуларны юкка чыгару срогын күрсәтеп, гамәлдәге законны бозуларны юкка чыгару турында үтәлүе мәҗбүри булган күрсәтмә бирә

\/

Гамәлдәге законны бозулар турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокта Министрлыкка аларны юкка чыгару турында мәгълүмат кермәгәндә, җаваплы эш башкаручы Министрлыкның юридик бүлегенә, гаепле затларны Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясындагы 1 өлеше Нигезендә җаваплылыкка тарту өчен нигезләрнең булуын раслаган материаллар һәм документлар белән, хезмәт язуын әзерләп җибәрә.
Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу турында эш кузгата".

Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга, тикшерүләр үткәрү, мәҗбүри үтәлергә тиешле күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр тутыру хокукы белән, күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итү буенча дәүләт функцияләрен башкару буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламентына №4 кушымта

(Үрнәк форма)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү

һәм социаль яклау министрлыгы хаты бланкында

Ачыкланган закон бозуларны бетерү турында

КҮРСӘТМӘ № __

“__”________ 20__ ел

(күрсәтмәне бирү урыны: торак пункт атамасы)

(эш бирүченең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, тулы атамасы)

“__” ________ ел. дан “__” ________ ел. га кадәрге чорда

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ________________________________________________________________ вазыйфаи затлары тарафыннан

тикшерү үткәрелде

________________________________________________________________

________________________________________________________________

(эш бирүчеләрнең билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә кабул итү турындагы законны үтәвен, билгеләп куелган квота чикләрендә инвалидларны эшкә урнаштыру өлкәсендә закон бозуларны ачыклау)

________________________________________________________________

(эш бирүченең тулы атамасы)

“Россия Федерациясендә халык мәшгульлеге турында” 19.04.1991 № 1032-1 законына туры китереп һәм “__” ________ 20__ ел, № __ тикшерү акты нигезендә, ачыкланган бозуларны бетерергә һәм түбәндәге таләпләрне үтәргә боерам:

| Т-п № | Закон бозуларны бетерү турында тикшерү актында күрсәтелгән таләпләр исемлеге |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

________________________ ________________________ ____________

(күрсәтмә чыгарган затның вазыйфа атамасы) (Ф.И.О.) (имза)

Үтәү өчен күрсәтмәне алдым:

________________ ________________________ ____________

(вазыйфа) (Ф.И.О.) (имза)